ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Мәгариф турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 20 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 7; 2014, № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 3 (I өлеш), № 40 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 54 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 26 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2021, № 36 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 24 (I өлеш), № 49 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 90 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 28 (I өлеш), № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле $8^1$ пункт өстәргә:
«$8^1$) Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларында спорт әзерлеге буенча өстәмә уку-укыту программалары нигезендә өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру;»;

2) 3 өлештә «балаларга өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итәргә,» сүзләреннән соң «спорт әзерлеге буенча өстәмә уку-укыту программалары нигезендә өлкәннәргә өстәмә белем бирүгә дәүләт ярдәме күрсәтергә, шул исәптән муниципаль мәгариф оешмаларында гамәлгә ашырыла торган спорт әзерлеге буенча өстәмә уку-укыту программалары нигезендә өлкәннәргә өстәмә белем бирүне финанс белән тәэмин итәргә,» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 2 өлешенең $8^{1}$ пункты һәм 3 өлеше нигезләмәләренең (әлеге Закон редакциясендә) гамәлдә булуы 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2025 ел, 05 март
№ 14-ТРЗ